| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.10.2023 Балык Бистәсе штп. № 349пи

2024 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елга расларга:

- Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;
- балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга 0,65 күләмендә төзәтмә коэффициентны.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган нормативлар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д. А. Сатдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 12 октябрендәге 349 пи номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнар ( 1 укучыга елына, сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | биш еллык уку срогы | җиде еллык уку срогы | Башлан-гыч һөнәри юнәлеш |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 74 988 | 85 669 | 110 026 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 79 714 | 91 055 | 116 878 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 39 699 | | 35 247 | 84 588 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 42 126 | | 37 425 | 89 801 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 83 632 | 68 869 | 252 446 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 88 953 | 73 250 | 268 494 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 35 168 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 37 395 | | |
| Фольклор сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 76 896 | 73 832 | 118 624 |
| Фольклор сәнгать | авыл җирлеге | | | 81 803 | 78 547 | 126 162 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 115 796 | | 111 004 | | 182 027 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 123 091 | | 118 014 | | 193 471 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 59 697 | | 55 573 | 55 492 | 83 712 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 63 434 | | 59 063 | 58 977 | 88 859 |